ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 02 » февраль 2023 ел — № 2

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Наласа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү хезмәтләре күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 30 гыйнварындагы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 2023 елның 01 февраленнән 7793 сум 48 тиен күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында” 01.02.2022 ел, №2 карарын 2023 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Наласа авыл җирлеге башлыгы — И.Р.Шакирова

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2023ел, №2
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 5160,41 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 623,22 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2009,85 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Наласа авыл җирлеге
башкарма комитетының
02.02.2023ел, №2
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җәсәдне киендерү | 280,43 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4879,98 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 623,22 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2009,85 |
| **Барлыгы** | **7793,48** |